ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар чыгару – табигый рәвештә яисә беренчел эшкәртүдән (чистартканнан, баетканнан) соң сәнәгатьтә файдалану һәм башка төрдәге хуҗалык файдалануы максатларында җир астыннан файдалы казылмаларны чыгару;»;

б) утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ятма – запаслары исәпләнгән һәм (яисә) разведкалау нәтиҗәсендә бәяләнгән файдалы казылманың (файдалы казылмаларның) табигый тупланмасы булган җир асты өлеше;»;

в) утыз икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«минераль чимал – файдалы казылма (файдалы казылмалар) булган һәм беренчел эшкәртелгән (чистартылган, баетылган) җир өстенә чыгарылган җир асты өлеше (тау токымы, руда чималы һәм башкалар);»;

г) илле алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар – җир астындагы каты, сыек яисә газ хәлендә булган, химик составы һәм физик үзлекләре аларны табигый рәвештә яисә беренчел эшкәртүдән (чистартканнан, баетканнан) соң сәнәгатьтә файдалану һәм башка

төрдәге хуҗалык файдалануы мөмкинлеген бирә торган, органик булмаган рәвештә яисә органик рәвештә барлыкка килгән табигый минераль катламнар;»;

д) алтмышынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирне бозу – ашламаларны, үсемлекләр өчен үсеш стимуляторларын, агулы химикатларны һәм башка куркыныч химик яисә биологик матдәләрне саклаганда, кулланганда һәм транспортировкалаганда алар белән эш итү кагыйдәләрен бозу аркасында кеше сәламәтлегенә яисә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерерлек итеп хуҗалык эшчәнлегенең яисә башка эшчәнлекнең зарарлы продуктлары белән җирне агулау, пычрату һәм башкача бозу;»;

2) 161 статьяның 1 өлешендә «барлыкка килгән,» сүзләреннән соң «эшкәртелгән,» сүзен өстәргә, «калдыкларның» сүзен «җитештерү һәм куллану калдыкларының» сүзләренә алмаштырырга;

3) 166 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«166 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалауга таләпләр**

1. Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалау экология таләпләрен, санитария-эпидемиология таләпләрен һәм автомобиль, тимер юл, һава, эчке сулар һәм диңгез транспорты турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

2. Җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалауны оештыру түбәндәге шартларны үтәп башкарылырга тиеш:

I – IV класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалаганда җитештерү һәм куллану калдыкларының паспорты булу;

йөк ташу кагыйдәләре нигезендә рәсмиләштерелгән, транспортировкалана торган җитештерү һәм куллану калдыкларының санын, аларны транспортировкалауның максатын һәм илтеп җиткерү урынын күрсәтеп, җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалау һәм тапшыру өчен документларның булуы;

транспорт чараларында җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалауга карата иминлек таләпләрен үтәү;

җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалаганда кулланыла торган транспорт чараларында, контейнерларда, цистерналарда җитештерү һәм куллану калдыкларының билгеләнгән хәвефлелек классын күрсәтүче махсус аеру билгеләре булу.

3. Җитештерү һәм куллану калдыкларының билгеләнгән хәвефлелек классын күрсәтүче махсус аеру билгеләренең үрнәкләре, шулай ук мондый билгеләрне җитештерү һәм куллану калдыкларын транспортировкалаганда кулланыла торган транспорт чараларына, контейнерларга, цистерналарга төшерү тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 20 июнь
№ 53-ТРЗ